ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына һәм Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 27 сентябрендә
кабул ителде

## 1 статья

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш), № 96 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 47 (I өлеш), № 56 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле $3^{1}$ өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«$3^{1}$. Муниципаль берәмлек уставында муниципаль берәмлек вәкиллекле органының җирле администрацияне формалаштыруда, шул исәптән җирле администрация башлыгы урынбасарларын, җирле администрациянең тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләп куюны раслауда яисә килештерүдә, катнашу, шулай ук мондый катнашуның рәвешләре һәм тәртибе каралырга мөмкин.».

**2 статья**

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына 3 нче кушымтаның 3.2.5 пунктына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 49 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 34 (I өлеш), № 47 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3.2.5. башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфадан азат итә, үз урынбасарлары арасында йөкләмәләрне бүлә, башкарма комитеттагы муниципаль хезмәткәрләрне һәм башка хезмәткәрләрне вазыйфага билгеләп куя һәм вазыйфадан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга карата кызыксындыру чаралары һәм дисциплинар җаваплылык чаралары куллана (устав нигезендә башкарма комитет җитәкчесе урынбасарларын, башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм (яисә) территориаль органнары җитәкчеләрен вазыйфага билгеләп кую муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы белән килештереп башкарыла);».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2024 ел, 12 октябрь
№ 80-ТРЗ